КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 февраль г.Казань № 119

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре Идел буе районының 36 нчы кичке (сменалы) урта гомуми белем бирү мәктәбе дәүләт белем учреждениесен муниципаль милектән Татарстан Республикасы милкенә тапшыру һәм эшләп торучы дәүләт белем бирү учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «36 нчы кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт казна гомуми белем учреждениесен оештыру турында» 2012 ел, 9 июль, 590 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре Идел буе районының 36 нчы кичке (сменалы) урта гомуми белем бирү мәктәбе дәүләт белем учреждениесен муниципаль милектән Татарстан Республикасы милкенә тапшыру һәм эшләп торучы дәүләт белем бирү учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «36 нчы кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт казна гомуми белем учреждениесен оештыру турында» 2012 ел, 9 июль, 590 нчы карарына, преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Гражданнарның белем алуга конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру, җәзага тартылган затлар тарафыннан гомуми белем алу өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 1 өлешенең 29 пункты, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 80 статьясы, «Иректән мәхрүм итү рәвешендәге җинаять

җәзаларын үтәүче учреждениеләр һәм органнар турында» 1993 елның 21 июлендәге 5473-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 16 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин